ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $15^3$ пункт өстәргә:

«$15^3$) Федераль законның $71^1$ статьясындагы 7 өлешенә нигезләнеп, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма тарафыннан гражданны эшкә урнаштыру буенча йөкләмәләрне үтәмәгән өчен аны максатчан укытуга тотылган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын каплауның күләмен һәм срокларын билгеләү тәртибен, максатчан укыту турындагы шартнамәнең якларын күрсәтелгән чыгымнарны каплаудан азат итү тәртибен һәм нигезләрен билгеләү;»;

2) 6 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктында «таләпләре, мәгариф стандартлары,» сүзләреннән соң «югары белем мәгариф оешмалары тарафыннан билгеләнә торган таләпләр,» сүзләрен өстәргә;

3) 10 статьяның 1 өлешендә «мәгариф стандартларын,» сүзләреннән соң «аспирантурада (адъюнктурада) фәнни һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программаларына карата федераль дәүләт таләпләрен,» сүзләрен өстәргә;

4) 19 статьяда:

а) 1 өлештә «һәм юнәлешләр» сүзләрен «, әзерлек юнәлешләре һәм фәнни белгечлекләр» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «әгәр әлеге статьяда башкасы билгеләнмәгән булса, урта һөнәри һәм югары белемнең дәүләт аккредитациясе булган уку-укыту программалары нигезендә белем бирү өчен һөнәрләр, белгечлекләр, әзерлек юнәлешләре һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең, әзерлек юнәлешләренең гомумиләштерелгән төркемнәре» сүзләрен «әгәр әлеге статьяда башкасы билгеләнмәгән булса, урта һөнәри һәм югары белемнең дәүләт аккредитациясе булган уку-укыту программалары нигезендә белем бирү өчен һөнәрләр, белгечлекләр, әзерлек юнәлешләре һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең, әзерлек юнәлешләренең гомумиләштерелгән төркемнәре, шулай ук аспирантурада (адъюнктурада) фәнни һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары нигезендә белем бирү өчен фәнни белгечлекләр» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясындагы 2 – 4 пунктларыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 – 4 пунктлары 2021 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 05 май
№ 33-ТРЗ